# Ватаным өчен –

# гомерем, көчем…



Еллар миннән үзенең соравын
Баганага терәп сорады.
Еллар минем күңел сафлыгын
Утка-суга салып сынады.

Ф.Кәрим

Фатих Кәрим - әдәбиятыбыз тарихында җуелмас якты эз калдырган шагыйрь.

Гыйнвар аенда шагыйрь Ф. Кәримгә 102 яшь тулган булыр иде.

Солдат-шагыйрь Ф.Кәрим иҗатына багышланган журналыбызның беренче сәхифәсен ачабыз.

**“Димдә тудым, Димдә үстем, Җиләк җыйдым тугайда...”**



Бөек шагыйрь 1909 елның 9 гыйнварында Башкортостанның Бишбүләк районында, ямьле Дим буенда урнашкан Ает авылында дөньяга килә.

Ул заманы өчен укымышлы саналган гаиләдә үсә. Абыйсы шагыйрь Ярлы Кәрим – Октябрь революциясе өчен актив көрәшкән коммунист. Әнисе һәм апасы да әдәбият белән кызыксыналар, үзләре җырлар чыгаралар. Ф. Кәримнең поэзиягә булган мәхәббәте дә ата-ана нигезендә үк сиземләнә башлый.

Икенче сәхифә

**“Гамьсез гомер өчен**
**тумадым мин,**
**Ялкынланып яшәү –**
**теләгем...”**

Укырга-язарга Фатих мәктәпкә барганчы ук өйрәнә. 1919-20 елларда авылдагы беренче баскыч мәктәптә белем ала. Алга таба Бәләбәйдәге педагогия техникумында укый , 1929 елда Казанда җир төзү эшләре техникумын тәмамлый.



Ф.Кәрим, Г.Минский (1928 ел)

Ф.Кәримнең әдәбият белән ныклап кызыксынуы әтисе үлгәч башлана. Бәләбәй педагогия техникумында укыганда шигырьләрен кульязма журналга кертә башлый. 1924 елда Казанга килгәч, аларны балалар матбугатында бастыра. Аннары бөтенләй газета-журналларда эшләүгә күчә.

# Өченче сәхифә

**«Өзелергә җитеп**
**сыкрый күңелем...»**

Татарстан китап нәшриятының яшьләр һәм балалар әдәбияты бүлегенә җитәкчелек иткән елларда ул аеруча канатланып иҗат итә. Ләкин 1937 елда Ф. Кәрим кулга алына. Мулла улы буларак, имеш, ул сыйнфый көрәшкә зыян китергән: троцкистлар белән элемтәдә торган.





Халык дошманы...

Хөкем карары:

ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә...

Ике сабый баласы белән, аяз көндә яшен суккандай, аптырап калган ана кая барырга, кемгә сыенырга, нәрсә эшләргә белми. Бер мәлгә шулай миңгерәп кала Кадрия, Ф.Кәримнең тормыш иптәше. Аннан исен-акылын җыеп, ирен коткаруның нинди генә юлларын эзләми дә, кемнәргә генә мөрәҗәгать итми.

1941 елның 12 ноябрендә «Дело за недоказанностью прекратить, из-под стражи освободить», дигән боерык бирелә һәм бу карар Мәскәүдә раслангач, 1941 елның 1 декабрендә Ф.Кәримне төрмәдән чыгаралар. Ләкин шундый шарт белән: Ф.Кәрим үз теләге белән фронтка китәргә тиеш!


# Дүртенче сәхифә

**“Бөек җыр ул –**

**Бөек Ватан өчен**

**Сугыш кырларында үлүе.”**





Полевая почта 08644
Каримову Фатых Валеевичу

Казань
Миславского 9 к 22

Үзенең күпсанлы каләмдәшләре кебек, Фатих Кәрим дә Бөек Ватан сугышында шагыйрь булып кына түгел, солдат булып та катнашты. 1941 елның ахырыннан алып 1945 елның 19 февраленә, батырларча һәлак булуына кадәр, ул Мәскәүдән алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сузылган солдат юлын уза һәм шушы көрәш юлын үз шигырьләрендә гәүдәләндерә.


Кызлары Ада белән Ләйлә Фатих Кәрим өчен күзләренең карасына тиң дәрәҗәдә газиз, шул дәрәҗәдә кыйммәт булган. Моны аның сугыш кырларыннан язылган хатлары дәлилләп тора.

«Кызым минем, Ләйләм!

Сиңа әтиеңнән кайнар сәлам. Мин сине бик сагындым, күрәсем килә...

Йә, Ләйлә, ничек яшисең, балалар бакчасында ниләр эшлисең? Әниеңә ничек булышасың? Сез әниегезне яратыгыз. Адага да әйт, әниегез моңаймасын. Аңа булышыгыз, сүзен тыңлагыз...»

# Кызларының әтиләренә язган хаты



ДОРОГОЙ. ПАПА
БЕЙ. ВРОГА
ПАПА. У МЕНЯ ЕСЪ
ТОЖОЙ ВОПРОС
ПЕШЫ СКОРЕ ПИСМО
ЛЕЙЛЯ КАРИМОВА

ЗДРАВСТВУЙ ПАПОЧКА [illegible] МЫ
ПОЛУЧИЛИ ТВОЁ ПИСМО И ОЧЕНЬ
АБРАДОВАЛИСЬ ПАПОЧКА ПРИЕЗЖАЙ
ПОСТАРАЕСЯ НИ ЗАДЕРЖОВАЦА
ПАПА. МЫ УЖЕ УЧЕМСЯ ВТОРОЙ
МЕСЯЧ Я В IБ, А ЛЕЙЛЯ I В У ЛЕЙ.
ПО АРИФМЕТИКЕ ПОЛУЧИЛА 5. ПО ПИСЬ-
МУ Ч. Я ПО ЧЧЕНЮ 5. ПО ПИСЬМУ 5. ПО
АРИФМЕТИКЕ 5. ПАПА У МЕНЯ И
ЛЕЙЛИ НЕТ ПОРТФЕЛЯ. ПАПА
ДОСВИДАНЯ ПИШИ ПОЧАЩЕ
ПИСМА. КАРИМОВА АДА ТВОЯ ДОЧ



Шагыйрьнең тормыш иптәше Кадрия
һәм кызлары Ләйлә, Ада

Ф.Кәрим сугыш елларында чын мәгънәсендә иҗади батырлык үрнәге күрсәтте. Өч ел вакыт эчендә ул һәркайсы әдәби казаныш саналырлык 150 ләп шигырь, 8 поэма, 2 прозаик повесть, «Шакир Шигаев» исемле зур драма әсәре иҗат итте. Аларда халкыбызның күпсанлы образлары гәүдәләнде.

Фатих Кәрим

# Гүзәл әнкәй

Сабый чагым иде, әнкәй бер көн
Миңа юка кулъяулык кигезде;
Кочаклады мине, кашларымны
Маңгаема иркен тигезде.

Кайнар иде җанда маңгаема,
(Ике алган сине кочканым!)
Ягъни йөрәк пышылдады серләрен:
— Кем булырсың икән, син балам!

Гүзәл әнкәй, хәзер исән булсаң,
Күр сугышка салган кулыңны,
Кайгы белән шатлык арасында
Көтәр идең сагынып улыңны.

Миңа озын гомер теләп-теләп,
Кем булыр, дип, улым-акыллым,
Өйдән эзгә йөрәк уктыйлар иде,
Окоплардан язган хатларымны.

Халкым өчен халык Ватанында
Ут салганда дошман үзере,
«Батырларча җиңде сабган улың»
Әзләнү шундый хәбәр китерсә,

Үлсәм дә бит эзсез калмас идем,
Кайгы дәртләр иде башыңда,
Вөҗданың саф булыр иде мәңге,
Табигый йөзе калыр каршыңда.

1.V.43. [illegible]

Ф.Кәрим Ватан сугышында чыннан да зур батырлыклар күрсәтә. Сугыш дәвамында ул ике тапкыр каты яралана, ләкин госпитальдән соң яңадан сугышка омтыла. Оста сугышуы өчен ул күп тапкыр язма котлаулар ала, фронтта рядовойдан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә.

1945нче елның 19нчы февралендә Фатих Кәрим сугышта һәлак була. Хәрби батырлыклары өчен аңа Югары Башкомандование тарафыннан бер-бер артлы өч тапкыр рәхмәт белдерелә, соңрак Кызыл Йолдыз ордены, I дәрәҗә Дан ордены һәм берничә медаль белән бүләкләнә ул.

Аның кайсы шигырен алып карасаң да, Ватанны көчле ярату сизелеп тора. Атаклы “Кыңгыраулы яшел гармун”да Фазыл: **Ватаным өчен –**

**Гомерем, көчем, –**

дип җырлый. Ул – аның якты киләчәккә ышаныч белән сугарылган без белгән әсәрләренең берсе генә. Сюжетлы шигырьгә җыр җырлату аша булса да, Ф.Кәрим иҗатының бик кыска рәвешкә китерелгән төп фикерен кертеп җибәрә.

Бүгенге көндә минем милләтем — Муса Җәлиле, Фатих Кәриме, Абдулла Алишы булган бөек милләт ул. Алар безнең горурлыгыбыз, мактанычыбыз, кешелек дәрәҗәбез. Фатих Кәрим урамы, Фатих Кәрим премиясе... Шагыйрь иҗаты, шөкер, мәңгеләштерелгән. Бу шулай булырга тиеш тә.


Исеме
калды
данга күмелеп